ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 187 от « 06 » 09 2024 г.

Район башлыгының 2021 елның
28 маендагы 119 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы, «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе субъектында - федераль әһәмияттәге Мәскәүдә ясалма интеллект технологияләрен эшләү һәм кертү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында махсус җайга салуны билгеләү буенча эксперимент үткәрү һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 6 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 08 августындагы №233-ФЗ федераль законнар нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына шикаять яисә гариза белән мөрәҗәгать иткән гражданнарның шәхси белешмәләрен җыю, эшкәртү һәм яклау тәртибен билгеләү максатларында карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының шәхси мәгълүматларын эшкәртү куркынычсызлыгы сәясәтен раслау турында» 2021 елның 28 маендагы 119 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 6.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 3.1 пункт өстәргә:

"3.1) составында мәгълүматны юк итү функциясе гамәлгә ашырылган мәгълүматны саклау чараларының туры килүен бәяләү процедурасын билгеләнгән тәртиптә узган шәхси мәгълүматларны юк итү өчен куллану;".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адрес буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында шәхси мәгълүматларны эшкәртүне оештыру өчен җаваплы затка йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары Р.Р. Самигуллин

000208